| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_09_» ____12___ 2019 г. № _375_

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантияләрен бирүгә бәйле аерым мәсьәләләре турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115, $115^2$ һәм $115^3$ статьялары һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 37 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбәндәге кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә принципалның финанс хәле анализын ясау, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәннән соң принципалның финанс хәле мониторингын үткәрү тәртибе;

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясен биргәндә тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәннән соң бирелгән тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясе буенча принципалга гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү тәртибе.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясенең гамәлдә булу вакыты дәвамында гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең җитәрлек булмавын ачыклаганда (шул исәптән принципалның, принципалга карата гарантның регресс таләбен үтәүне тәэмин итү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүгә банк гарантиясе яисә поручительлек биргән юридик затның финанс хәле сизелерлек начарайган очракта, залог предметының базар бәясен киметкән очракта) 90 көн дәвамында принципал тарафыннан тәэмин итүне (тулы яки өлешчә) алмаштыру гамәлгә

ашырыла яисә составын һәм тәэмин итүнең гомуми күләмен (суммасын) Россия Федерациясе Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Бюджет кодексында һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китерү максатларында өстәмә (җитмәгән суммага) тәэмин итү бирелә дип билгеләргә.

3. Акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районынына караган хуҗалык җәмгыяте булган яисә йөкләмәләре буенча Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясе бирелгән, мөлкәте Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган муниципаль унитар предприятие булган принципалны тулысынча яисә өлешчә хосусыйлаштыру очрагында, хосусыйлаштыру тәмамланган көннән алып 90 көн эчендә принципал гарантиянең тулы күләмендә яисә нинди дә булса өлешендә үтәлүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган гарантның регресс таләпләрен канәгатьләндерү буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының $115^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе граждан законнарының тиешле таләпләренә җавап биргән үз йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы Рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының 2019
елның «_09_»___12____

_375_ номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә принципалның финанс хәле анализын, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәннән соң принципалның финанс хәле мониторингын гамәлгә ашыру Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә принципалның финанс хәлен анализлауны (алга таба — башлангыч анализ), шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәннән соң принципалның финанс хәле мониторингын (алга таба — алдагы анализ) гамәлгә ашыруга таләпләрне билгели.

2. Принципалның финанс хәленең башлангыч анализы Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясе (алга таба — гарантия) бирелгәнчегә кадәр гамәлгә ашырыла.

3. Принципалның финанс хәленең алдагы анализы гарантия бирү вакыты дәвамында гарантия биргәннән соң ел саен гарантия буенча йөкләмәләр туктатылганчы, Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Принципалның финанс хәленең алдагы анализын гамәлгә ашыру әлеге карар белән расланган муниципаль гарантия алу өчен принципал тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге буенча принципал тарафыннан тапшырыла торган документларны анализлау нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Принципалның финанс хәленең алдагы анализы агымдагы елның 1 маеннан да соңга калмыйча Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына принципал тарафыннан тапшырыла торган түбәндәге документлар нигезендә башкарыла:

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган формалар буенча соңгы хисап елында принципал эшчәнлеге турында бухгалтер хисабы күчермәләре һәм аларны кабул итү турында (яисә аларны электрон рәвештә кабул итү турында территориаль салым органына хәбәр итеп) территориаль салым органы тамгалары белән аңлатма язулары;

иң зур дебиторларны һәм кредиторларны (гомуми бурычның биш проценттан артыгын) һәм аны түләү вакытларын күрсәтеп, агымдагы ел башына һәм агымдагы елның соңгы хисап чоры ахырына дебиторлык һәм кредиторлык бурычларын расшифровкалары;

хисап елы өчен принципалның бухгалтерлык хисаплылыгының дөреслеге турында аудиторлык бәяләмәсенең нотариаль расланган күчермәсе (Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри еллык аудиторлык тикшерүе үткәрелергә тиешле икътисадый субъектларга кагыла);

салым органының барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салым һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча принципалның бурычы булмау турында аны тапшыру датасына кадәр 14 көннән дә иртәрәк булмаган вакытта алынган белешмәләре;

соңгы хисап датасына һәм агымдагы ел башына принципалның чиста активлары бәясен исәпләү.

6. Принципалның финанс хәлен бәяләү әлеге Тәртипнең кушымтасында каралган принципалның финанс хәлен бәяләү Методикасына таянып финанс күрсәткечләр нигезендә үткәрелә.

7. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан принципалның финанс хәленең башлангыч һәм алдагы анализлары нәтиҗәләре буенча тиешле бәяләмәләр төзелә.

8. Принципалның финанс хәлен анализлау, аның нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзү һәм Балтач муниципаль районының Балтач район башкарма комитетына бәяләмәне бирү әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында каралган документларны принципал биргән көннән алып 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә принципалның финанс хәле анализын, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәннән соң принципалның финанс хәле мониторингын гамәлгә ашыру Тәртибенә кушымта

Принципалның финанс хәлен бәяләү методикасы

1.1. Принципалның финанс хәлен бәяләү өчен, бухгалтерлык балансы һәм финанс нәтиҗәләре турындагы хисап нигезендә исәпләнелә торган төп финанс индикаторларының түбәндәге өч төркеме кулланыла:

ликвидлык коэффициенты;

үз һәм заем акчалары нисбәте коэффициенты;

рентабельлек күрсәткече.

2. Ликвидлык коэффициенты.

2.1. Ликвидлык коэффициентлары төркеме өч күрсәткечтән тора:

абсолют ликвидлык коэффициенты;

тиз ликвидлык коэффициенты;

агымдагы ликвидлык коэффициенты.

2.2. Абсолют ликвидлык коэффициенты (К1) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_1 = \frac{\text{ден.средства}(1250) + \text{кр.фин.вложения}(1240)}{\text{тек.обязательсва}(1500 - 1530 - 1540)},$$

биредә

акча(1250) - кассадагы һәм исәп-хисап счетындагы акча (бухгалтерлык балансының юл коды 1250),

кыс.фин.кертемнәр(1240) - хисап чоры ахырына кадәр формалашкан кыска вакытлы финанс чыгымнары (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ. б.) суммасы (бухгалтерлык балансының юл коды 1240),

агым.йөкләмәләр(1500-1530-1540) - хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк вакыт түләп бетерү срогы белән кыска вакытлы финанс йөкләмәләре. Күрсәткеч бухгалтерлык балансының V бүлеге нәтиҗәсенең (бухгалтерлык балансының юл коды 1500), булачак чорларның керемнәренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1530) һәм бәяләү йөкләмәләренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1540) аермасы буларак табыла.

2.3. Тиз ликвидлылык коэффициенты (К2) хуҗалык әйләнешеннән оператив рәвештә акча чыгару һәм булган финанс йөкләмәләрен түхләү сәләтен характерлый. Күрсәткеч түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_2 = \frac{\text{деб.задолженность}(1230) + \text{кр.фин.вложения}(1240) + \text{ден.средства}(1250)}{\text{тек.обязательства}(1500 - 1530 - 1540)},$$

биредә

деб.бурычы (1230) - дебиторлык бурычы, аны түләү ел дәвамында көтелә (бухгалтерлык балансының юл коды 1230),

кыс.фин.кертемнәр(1240) - хисап чоры ахырына кадәр формалашкан кыска вакытлы финанс чыгымнары (акцияләр, вексельләр, облигацияләр, бирелгән займнар һ. б.) суммасы (бухгалтерлык балансының юл коды 1240),

акча(1250) - кассадагы һәм исәп-хисап счетындагы акча (бухгалтерлык балансының юл коды 1250),

агым.йөкләмәләр(1500-1530-1540) - хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк вакыт түләп бетерү срогы белән кыска вакытлы финанс йөкләмәләре. Күрсәткеч бухгалтерлык балансының V бүлеге нәтиҗәсенең (бухгалтерлык балансының юл коды 1500), булачак чорларның керемнәренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1530) һәм бәяләү йөкләмәләренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1540) аермасы буларак табыла.

2.4. Агымдагы ликвидлык коэффициенты (К3) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_3 = \frac{\text{\textit{оборотн.активы}}(1200)}{\text{\textit{крат.обязательства}}(1500-1530)},$$

биредә

әйләнеш.активлар (1200) - әйләнештәге активлар (бухгалтерлык балансының юл коды 1200),

кыс.йөкләмәләр(1500-1530) - хисап датасыннан соң 12 айдан кимрәк вакыт түләп бетерү срогы белән кыска вакытлы финанс йөкләмәләре. Күрсәткеч бухгалтерлык балансының V бүлеге нәтиҗәсенең (бухгалтерлык балансының юл коды 1500) һәм булачак чорларның керемнәренең (бухгалтерлык балансының юл коды 1530) аермасы буларак табыла.

3. Үз һәм заем акчалары нисбәте коэффициенты;

3.1. Үз һәм заем акчалары нисбәте коэффициенты (К4) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_4 = \frac{\text{\textit{собственный капитал}}(1300)}{\text{\textit{заемный капитал}}(1500+1400-1530)},$$

биредә

үз капиталы(1300) - үз капиталы һәм резервлары (бухгалтерлык балансының юл коды 1300),

заем капиталы (1500+1400-1530) - финанс йөкләмәләре. Күрсәткеч булачак чорларның керемнәрен исәпкә алмыйча (бухгалтерлык балансының юл коды 1530) кыска вакытлы һәм озак вакытлы йөкләмәләр суммасы (бухгалтерлык балансының юл кодлары 1500 һәм 1400) буларак табыла.

4. Рентабельлек күрсәткече

4.1. Рентабельлек (К5) күрсәткечен исәпләү процедурасы сәүдә һәм башка оешмалар өчен аерылып тора.

4.2. Сәүдә оешмалары өчен рентабельлек күрсәткече продукциянең рентабельлеге финанс коэффициенты нигезендә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_5 = \frac{прибыль\,от\,продаж(2200)}{валовая\,прибыль(2100)},$$

биредә

сатудан кергән табыш (2200) - продукцияне сатудан кергән табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның юл коды 2200),

тулай табыш(2100) - тулай табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның юл коды 2100).

4.3. Сәүдә булмаган оешмалар өчен рентабельлек күрсәткече төп эшчәнлек рентабельлегенең финанс коэффициенты белән туры килә һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_5 = \frac{прибыль\,от\,продаж(2200)}{выручка(2110)},$$

биредә

сатудан кергән табыш (2200) - продукцияне сатудан кергән табыш (финанс нәтиҗәләре турында хисапның юл коды 2200),

Керем(2110) - керем (финанс нәтиҗәләре турында хисапның юл коды 2110).

5. Финанс хәлен бәяләү төзелеше.

5.1. Һәр база индикаторы өчен иң яхшы һәм иң начар чик күрсәткечләр билгеләнә.

5.2. Табылган күрсәткеч һәм чик күрсәткечләргә нигезләнеп, һәр күрсәткеч өчен өч категориянең берсе билгеләнә. Күрсәткечләрнең иң чик күрсәткечләре һәм күрсәткечнең факттагы күрсәткечләренә карап категорияне сайлау кагыйдәсе 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица. Күрсәткечләрнең иң чик күрсәткечләре һәм күрсәткечнең факттагы күрсәткечләренә карап категорияне сайлау кагыйдәсе.

| Коэффициентлар | 1 нче категория (яхшы күрсәткеч) | 2 нче категория (канәгатьләнерлек күрсәткеч) | 3 нче категория (канәгатьләнмәслек күрсәткеч) |
|---|---|---|---|
| К1 | 0,2 күбрәк | 0,1-0,2 | 0,1 кимрәк |
| К2 | 0,8 күбрәк | 0,5-0,8 | 0,5 кимрәк |
| К3 | 2,0 күбрәк | 1,0-2,0 | 1,0 кимрәк |
| К4 | | | |
| сәүдә предприятиеләре | 0,6 күбрәк | 0,4-0,6 | 0,4 кимрәк |
| башка тармак предприятиеләре | 1,0 күбрәк | 0,7-1,0 | 0,7 кимрәк |

| | | | |
|---|---|---|---|
| К5 | 0,15 күбрәк | 0,0-0,15 | 0,0 кимрәк (рентаб. түгел) |

5.3. Җыелма бәяләүнең күрсәткече (S) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S = Вес_1 \times Категория_1 + Вес_2 \times Категория_2 + Вес_3 \times Категория_3 + \\ + Вес_4 \times Категория_4 + Вес_5 \times Категория_5,$$

биредә

і авырлыгы - җыелма бәяләүдә Кі күрсәткеченең авырлыгы, і=1, 2, 3, 4 яки 5. Авырлык билгеләре 2 нче таблицада күрсәтелгән.

Категория і - К і күрсәткече кергән категория. Категория і: 1, 2 яки 3.

2 нче таблица. Җыелма бәяләүне исәпләгәндә кулланыла торган күрсәткечләрнең авырлыгы.

| Күрсәткеч | Күрсәткечнең авырлыгы |
|---|---|
| Абсолют ликвидлык коэффициенты (К1) | 0,11 |
| Тиз ликвидлык коэффициенты (К2) | 0,05 |
| Агымдагы ликвидлык коэффициенты (К3) | 0,42 |
| Үз һәм заем акчалары нисбәте (К4) | 0,21 |
| Рентабельлек коэффициенты (К5) | 0,21 |

5.4. Җыелма бәяләүнең күрсәткече нигезендә принципалның финанс хәле дәрәҗәсе билгеләнә.

Принципалның финанс хәле түбәндәге дәрәҗәләрнең берсенә ия булырга мөмкин:

Әгәр җыелма бәяләү күрсәткече 1,05 артмаса - бу финанс хәленең яхшы дәрәҗәсе;

Әгәр җыелма бәяләү күрсәткече 1,05 артса, тик 2,4 кимрәк булса - бу финанс хәленең канәгатьләнерлек дәрәҗәсе;

Әгәр җыелма бәяләү күрсәткече 2,4 артса - бу финанс хәленең канәгатьләнмәслек дәрәҗәсе.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының 2019 елның «_09_»___12____
_375_ номерлы карары белән
расланды

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәннән соң тәэмин ителешнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын контрольдә тотуны гамәлгә ашыру
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантия (алга таба — гарантия) биргәндә тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне гамәлгә ашыру, шулай ук гарантия биргәннән соң бирелгән тәэмин ителешнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын контрольдә тоту таләпләрен билгели.

2. Тулы күләмдә яисә гарантиянең нинди дә булса өлешендә гарантның принципалга карата регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү сыйфатында түбәндәге тәэмин итүнең бер яисә берничә төре кабул ителергә мөмкин:

дәүләт яисә муниципаль гарантия;

юридик затның поручительлеге;

принципалның гарантия белән тәэмин ителә торган кредит буенча кредиторы булмаган кредит оешмасының банк гарантиясе;

принципалның яки өченче затның милек залогы.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы алдындагы акчалата йөкләмәләр буенча вакыты чыккан (җайга салынмаган) бурычлары булган юридик затларның банк гарантияләре һәм поручительлекләрен үтәүне, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнарын, җыемнарын, иминият кертемнәрен, пеняларын, штрафларын, процентларын, шулай ук банк гарантияләрен һәм чиста активларының бәясе бирелә торган банк гарантиясенең (тапшырыла торган поручительлекнең) өч тапкыр суммасын тәшкил иткән юридик затларның поручительлеген, бөлгенлек (банкротлык) турындагы эш буенча җитештерү кузгатылган юридик затларны, үзгәртеп оештыру яки бетерү процессында булган юридик затларны тәэмин итү сыйфатында кабул итү рөхсәт ителми.

4. Тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын тикшерү Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан гарантия бирелгәнче, шулай ук гарантия бирелгәннән соң бирелгән гарантиянең вакыты дәвамында гарантия буенча йөкләмәләр туктатылганчы ел саен 1 июньнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

5. Тәэмин итүнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясен алу өчен принципал тарафыннан тәкъдим ителергә тиешле документлар исемлеге буенча бирелә торган документларны анализлау һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясен бирү турында әлеге карар белән расланган шартнамә төзү нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Тәэмин итүнең җитәрлек булуын тикшерү, бирелә торган (бирелгән) тәэмин итүнең әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясе буенча принципалга карата гарантның регресс таләбе үтәлүне тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү тәртибендә каралган гарантия буенча принципалга карата гарантның регресс таләпләрен үтәүне тәэмин итү буенча принципалның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләменә (суммасына) карата куелган таләпләргә туры килүен билгеләүдән гыйбарәт.

7. Банк гарантиясе һәм поручительлекнең ышанычлылыгы банк яисә башка кредит оешмасының (алга таба — банк-гарант) һәм поручительнең финанс хәле тотрыклылыгы белән билгеләнә.

8. Банк-гарант бер үк вакытта түбәндәге таләпләргә туры килсә, банк-гарантның финанс хәле тотрыклы һәм банк гарантиясе ышанычлы дип таныла:

а) банк операцияләре башкаруга Россия Федерациясе Үзәк банкының генераль лицензиясе булу;

б) кредит оешмасының «Россия Федерациясе банкларында физик затларның кертемнәрен иминиятләштерү турында» 2003 елның 23 декабрендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе банкларында физик затларның кертемнәрен мәҗбүри иминиятләштерү системасында катнашуы;

в) активларның гомуми күләменең 50 процентыннан да ким булмаган күләмдә I, II категорияле активлары күләме булуы;

г) кредит оешмасының кимендә 1 млрд. сум күләмендә үз акчалары (капиталы) булуы;

д) мәҗбүри нормативларны үтәү буенча Россия Федерациясе Үзәк банкы таләбен үтәү (шул исәптән банк гарантиясе бирүгә бәйле кабул ителә торган бурыч йөкләнешен исәпкә алып);

е) соңгы хисап елында һәм агымдагы елның соңгы хисап чорында эшчәнлек нәтиҗәләре буенча зыяннар булмау;

кредит рейтингының Россия Федерациясе өчен кредит рейтинг агентлыгының Аналитик кредит рейтинг шкаласы буенча «A-(RU»)  дәрәҗәсенә караганда түбәнрәк булу яисә «Standard & Poor 's» яисә «Fitch Ratings» рейтинг агентлыгының Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча «ruA-(RU» кредит рейтинг агентлыгы дәрәҗәсенә караганда түбәнрәк яисә «Mods» рейтинг агентлыгы классификациясе буенча «ВВ-» дәрәҗәсенә түбәнрәк булмаган кредит рейтингы булу.

9. Поручительнең финанс хәлен бәяләү Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясе бирелгәндә принципалның

финанс хәлен анализлау тәртибенә кушымта булып торучы принципалның финанс хәлен бәяләү методикасы нигезендә, шулай ук әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясе бирелгәннән соң, принципалның финанс хәлен мониторинглау нигезендә гамәлгә ашырыла.

Әгәр поручительнең финанс хәле яхшы яки канәгатьләнерлек бәяләү дәрәҗәсенә ия булса, шулай ук кредит рейтингы (кредит рейтинглары) булган очракта поручитель Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча Аналитик Кредит Рейтинг Агентлыгының (акционер җәмгыять) Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча «A-(RU)» дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаса яисә «Эксперт РА» рейтинг агентлыгының Россия Федерациясе өчен милли рейтинг шкаласы буенча «ruA-» дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаса, кредит рейтингы «Standard & Poor's» яки «Fitch Ratings» рейтинг агентлыклары классификациясе буенча «BB-» дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаса яисә "Moody's" рейтинг агентлыгы классификациясе буенча "Ba3" дәрәҗәсеннән түбәнрәк булмаса, поручительнең финанс хәле тотрыклы дип һәм поручительлек ышанычлы дип таныла.

11. Принципалга карата гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал яисә өченче зат тарафыннан залогка бирелә торган (бирелгән) мөлкәтне бәяләү һәм әлеге мөлкәтнең ликвидлык дәрәҗәсен билгеләү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 932 статьясындагы 3 пунктының җиденче абзацы нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасы, тәэмин итүнең җитәрлеклеген, ышанычлылыгын һәм ликвидлылыгын тикшергәннән соң, 10 көн эчендә тиешле бәяләмәне Татарстан Республикасының Балтач район башкарма комитетына тапшыра.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының 2019 елның «_09_»___12____
_375_ номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясе буенча принципалга гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләмен (суммасын) билгеләү Тәртибе.

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясен биргәндә, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясенең гамәлдә булу вакыты дәвамында, принципалга карата гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләменә (суммасына) таләпләрне билгели.

2. Принципалга карата гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең минималь күләме (алга таба-тәэмин итүнең минималь күләме) муниципаль гарантияне биргәндә, шулай ук әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясе бирелгәннән соң, принципалның финанс хәлен мониторинглау нигезендә, принципалның финанс хәлен бәяләү Тәртибенә кушымта булып торучы принципалның финанс хәлен бәяләү Методикасы нигезендә аның финанс хәленең канәгатьләнү дәрәҗәсенә карап билгеләнә.

3. Тәэмин итүнең минималь күләме түбәндәгеләргә туры килә:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясе суммасының 100 проценты дәрәҗәсе - принципалның финанс хәле яхшы дәрәҗәдә булганда;

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль гарантиясе суммасының 120 проценты дәрәҗәсе - принципалның финанс хәле дәрәҗәсе канәгатьләнерлек дәрәҗәдән югары булмаганда.

4. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль гарантиясе буенча принципалга гарантның регресс таләбен канәгатьләндерү буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүнең гомуми күләменең (суммасының) тәэмин итүнең минималь күләменә туры килүен бәяләгәндә:

юридик затларның поручительстволары, банк гарантияләре, дәүләт (муниципаль) гарантияләре алар бирелгән суммада исәпкә алына;

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 93.2 статьясындагы 3 пунктының җиденче абзацы нигезендә бәяләнә торган залогка тапшырыла торган (тапшырылган) мөлкәтнең базар бәясенә 0,7 коэффициентын кулланып төзәтмәләр кертелергә тиеш.